Республика Татарстан
Совет Альметьевского
сельского поселения
Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге советы

РЕШЕНИЕ

2020ел, 18 март

КАРАР

№ 3

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советының «физик затлар милкенә салым турында» 2014 елның 17 ноябрендә кабул ителгән 17 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 52 статьясына һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 августындагы 334-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 321-ФЗ номерлы Федераль закон, Сарман районы прокуратурасының 2009 елның 16 декабрендәге 02-07-01/19 номерлы протесты, Әлмәт авыл җирлеге Уставына нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советының «физик затлар милкенә салым турында» 2014 елның 17 ноябрендәге 17 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1.1.Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән салым салу объектларында урнашкан урыннар;»

2) 2.1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1.2. хуҗалык төзелешләре яисә корылмалары, аларның һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмый һәм алар шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан;».

2.2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлмәт авыл җирлеге
Советы Рәисе

Д.Ә.Газизов